| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.02.2020 ел Баулы шәһәре №35

Баулы муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларын файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы (2019 елның 27 декабрендәге ред.), «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы (2009 елның 2 августындагы ред.) федераль законнар, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы (2019 елның 27 декабрендәге ред.) Россия Федерациясе Законы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы Баулы муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларын файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны "Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров